Республика Татарстан
Глава Бизякинского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423648, село Бизяки,
ул. Центральная. 46

Татарстан Республикасы
Менделеевск
муниципаль районы
Бәзәкә авыл жирлеге
башкарма комитеты
423648, Бәзәкә авылы
Узәк урам, 46

Тел./факс 3-47-34

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

5.12. 2022 ел №5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 17 декабре 14.00 сәгатьтә Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен үткәрү урыны - Татар Тәкәше авылы, Үзәк урамы, 26А йорты буенча урнашкан Татар Тәкәше авыл мәдәният йорты

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә 1 һәм 2 төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, балигъ булмаган күп балалаы гаиләләрдән, көндезге (көндезге) уку формасы студентларыннан, Россия Армиясенә хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереп, түбәндәге эшләрне башкаруга сез ризамы

- Кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Суүткәргеч торбаларны алыштыру буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү

« РИЗА» "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә - www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында - pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы:
И.И. Кәшәфетдинов